**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ**
**КАРАР**

15 февраль 2019 ел №155

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Өтәшкә авыл жирлеге” муниципаль берәмлегендә вакантлы вазифаларны алмаштыру буенча конкурс уздыру тәртибенең Кагыйдәләрен раслау турында»гы Зеленодольск муниципаль районы «Өтәшкә авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 13 сентябрендәге 135 нче карарына үзгәрешләр кертү турында.

Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл жирлеге башлыгы Тухтаркин Н.М. мәгълүматын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы (№25-ФЗ 02.03.2007 ел) Федераль законга яраклы рәвештә, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы Кодексы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл жирлеге Советы түбәндәге **карарны кабул итте:**

1.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы “Өтәшкә авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында вакантлы вазифаларны алмаштыру буенча конкурс уздыру тәртибе турындагы, Зеленодольск муниципаль районы “Өтәшкә авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган 2018 елның 13 сентяберендә 135 нче «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы “Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында вакантлы вазифаларны алмаштыру буенча конкурс уздыру тәртибенең Кагыйдәләрен раслау турында»гы Кагыйдәгә (алга таба - Кагыйдә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) Кагыйдәнең 4нче пунктының 5нче өлешендә «кечеләргә» сүзләрен «әйдәп баручылар» сүзләренә алмаштырырга;

1.2) 10нчы пунктны яңа редакциядә язарга:

«10. Бәйгедә катнашырга теләүчеләр, конкурс комиссиясенә түбәндәге документлар беркетелгән гариза тапшыралар:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең боерыгы белән расланган форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета;

2) паспорт;

3) хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелү очрагы булмаганда, хезмәт кенәгәсе;

4) белем турында документ;

5) хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелү очрагы булмаганда, пенсияне мәҗбүри иминиятләштерү таныклыгы;

6) физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органына учетка кую турында таныклык;

7) запастагы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен – хәрби учет документы;

8) муниципаль хезмәткә керешүгә киртә булмаслык авыруларның юклыгы турында медицина оешмасы биргән белешмә;

9) еллык , елдан алдагы календарь ел өчен керемнәр турында, гражданинның милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүмат;

10) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» (02.03.2007 ел, №25-ФЗ) Федераль законның 15.1 маддәсендә каралган мәгълүмат;

11) Федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында күрсәтелгән башка документлар;

1.3. Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Советының 2018 елның 13 сентябрендәге 135 нче номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районының " Өтәшкә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә)

2. Шушы карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокук порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталы составындагы Зеленодол муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Өтәшкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99 а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урам, 40 а йорт (мәдәният йорты бинасы)  урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Зеленодольск муниципаль районы  Өтәшкә авыл жирлеге  башлыгына йөкләргә.

Өтәшкә авыл жирлеге
башлыгы,  Совет рәисе — Н.М.Тухтаркин